МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ

№ 168 / о

«16» 11 2023

БОЕРЫК

Татарстан Республикасында суны җылытуга җылылык энергиясен тоту нормативларын раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта гомуми милекне кулланганда һәм тотканда кулланыла торган коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативларын һәм коммуналь ресурслардан файдалану нормативларын ачыклау һәм билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 23 маендагы 306 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 313 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Кушымтага ярашлы рәвештә 2024 елның 1 июленнән Татарстан Республикасында суны җылытуга җылылык энергиясен тоту нормативларын расларга һәм гамәлгә кертергә.
2. Суны җылыту өчен җылылык энергиясен тоту нормативлары аналог һәм исәпләү ысулларын кулланып билгеләнде.
3. Юридик бүлеккә (Р.И.Кузьминга), дәүләт теркәвенә алу өчен, әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.
4. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторына (Р.Җ.Зәйнуллинага) бу боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынган вакыттан ун эш көне эчендә аның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.
5. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасында кайнар су белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәт күрсәтү максатларында салкын суны җылытуга кулланыла торган җылылык энергиясе чыгымнары нормативларын раслау турында» 2017 елның 26 октябрендәге 189/о номерлы боерыгын 2024 елның 1 июленнән көчен югалткан дип танырга.

6. Бу боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

7. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрының беренче урынбасары А.М. Фроловка йөкләргә.

Министр М.М. Айзатуллин

МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫК МИНИСТРЛЫГЫ
Отдел контроля исполнения документов

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының « 16 »
__11__2023 №168/о
боерыгына кушымта

Татарстан Республикасында суны җылытуга җылылык энергиясен тоту нормативлары

Гкал/м$^3$

| Җылылык белән тәэмин итү системасы төре | Үзәкләштерелгән кайнар су белән тәэмин итү системасы белән |
|---|---|
| Ачык | |
| Изоляцияле терәкләр белән: | |
| сөлге киптергечләр белән | 0,0655* |
| сөлге киптергечләрдән башка | 0,0579** |
| Изоляцияләнмәгән терәкләр белән: | |
| сөлге киптергечләр белән | 0,0679** |
| сөлге киптергечләрдән башка | 0,0629** |
| Ябык | |
| Изоляцияле терәкләр белән: | |
| сөлге киптергечләр белән | 0,0651* |
| сөлге киптергечләрдән башка | 0,0601* |
| Изоляцияләнмәгән терәкләр белән: | |
| сөлге киптергечләр белән | 0,0711* |
| сөлге киптергечләрдән башка | 0,0659* |
| | |
| | Үзәкләштерелмәгән кайнар су белән тәэмин итү системасы белән |
| Изоляцияле терәкләр белән: | |
| сөлге киптергечләр белән | 0,0615* |
| сөлге киптергечләрдән башка | 0,0571* |
| Изоляцияләнмәгән терәкләр белән: | |
| сөлге киптергечләр белән | 0,0687* |
| сөлге киптергечләрдән башка | 0,0625* |

* аналог ысулын кулланып билгеләнгән
** исәпләү ысулын кулланып билгеләнгән